ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ

№ 9–10
27 август, 2022 ел

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШ
Авыр хәлдә калганнарга ярдәм
> 5

ЯРМИНКӘДӘ ОЧРАШУ
Өлкәннәр яхшы кәеф өләште
> 6

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР
Ташкабакның өлгергән чагы
> 8

БЕР ГАСЫРЛЫК ГОМЕР

Юбиляр

Әгерҗе районының иң өлкән кешесе Уразай авылында яши. 100 яшен тутырган тыл һәм хезмәт ветераны Маһинур Гобәшеваның тормыш юлы җиңелләрдән булмаган.

Һөнәре буенча күмер әзерләүче-яндыручы булган әтисе Шәймөхәммәт абзый гаиләсе белән Чаллы ягына эшкә китә. Шуңа күрә кечкенә Маһинурга башлангыч белемне рус мәктәбендә алырга туры килә. Җор телле, үткен, тырыш кыз русчага тиз өйрәнә. Әтисе авыргач, яңадан Уразайга кайтып, укуын Салагыш мәктәбендә дәвам иттерә.

Җиде сыйныфны тәмамлагач, язмыш җилләре аны Казанга илтә. Кыю, гел «5ле»гә укучы, нинди эшкә тотынса да булдыра торган тәвәккәл кыз, кичке мәктәпне тәмамлап, шәфкать туташлары әзерли торган ике еллык курсларда укый. 1941 елның май аенда кулына диплом алып, яслегә эшкә урнаша. Алга зур планнар куеп, матур гына эшләп йөргәндә, сугыш башлана. Аны ишеткәч, хәрби комиссариатка барып, фронтка китәргә гариза яза ул. 19 яшьлек кызны хәрби хәзерлек курсларына җибәрәләр. Пилотка, гимнастерка, ботинка бирәләр, мылтыктан атарга да өйрәтәләр. «Фронтка бүген китәбез, иртәгә китәбез», – дип, казармада яшәп, боерык көтеп торганда, фронттан яралылар күп кайтарылу сәбәпле, Казанга эвакуацияләнгән госпитальләргә эшкә билгеләнәләр.

– Мин хирургия бүлегендә эшләдем. Яралылар күп иде. Тәүлек буе күз йоммыйча эшләгән чаклар да күп булды, – дип искә ала Маһинур апа.

Еш кына баһадирдай ир-егетләрне беренче каттан бишенчегә – рентгенга күтәреп алып менәләр. «Ничек күтәрә алдык икән дип аптырыйм хәзер», – ди ул. Яралыларның гомерен саклап калу өчен, ун тапкыр донор булырга туры килә. Сугыш беткәч, туган якларына әйләнеп кайта ул. Нинди генә эшләр башкармый: шәфкать туташы, бухгалтер, сатучы да була, озак еллар ашханәдә эшли, фермада да хезмәт куя. «Аның кебек көчле рухлы, нык ихтыярлы, тәвәккәл, тормышны яратучылар сирәк», – дип соклана авылдашлары.

90 яшенә кадәр клуб сәхнәсендә җырлый ул. 95 яшьлек юбилеена баргач, якындагы урманга җәяү генә барып җиләк җыюы, аны авылдагы өлкән кешеләргә чыначлап таратып чыгуы турында шаккатып сөйләгәннәре хәтердә.

> 2

Соклану

ГЫЙЛЕМБАНУ ӘБИ: «БУ ЯШЬКӘ ҖИТӘРМЕН ДИМӘГӘН ИДЕМ»

Күптән түгел 95 яшен тутырган Гыйлембану апа Зыятдинова Балтач районының Түнтәр авылында гомер итә.

Район башлыгы урынбасары Наил Сабирҗанов, социаль яклау бүлеге җитәкчесе Алсу Гатиятуллина һәм башкалар юбилярны гомер бәйрәме белән котлап, изге теләкләрен җиткерделәр. Россия Президенты Владимир Путинның котлау хатын, бүләк-күчтәнәчләр тапшырдылар.

– Балачагыбыз булмады, яшьлекне күрмәдек без. 3 нче классны тәмамлаган елны колхоз басуына билчән утарга алып чыктылар. Шул елдан колхозда эшли башладым. Бәрбаш, Шәмәрдән, Арча якларыннан, арба-чана тартып, симәнә ташулар шактый эләкте. Әтием Кариле тау башына килеп каршы ала торган иде. Авыр хезмәттә үстек, ачлыгын-юклыгын кичердек, – дип искә ала ул. – 7 нче классны бетергән елны авылдагы 13–15 яшьлек балаларны ФЗӨгә алдылар. Безне Шәмәрдәнгә таба алып киттеләр. Анда товар поезды вагоннарына төркемнәргә бүлеп төяделәр. Сезне укырга җибәрәләр, дигәннәр иде, уку булмады ул: Казанда заводта авыр эшкә юлладылар. Сугыш чоры заводта эшләп үтте. Башта өйрәнчек булып йөрсәк, соңга таба эшче булып санала башладык. 1948 елны авылга кайтып эшли башладым.

Ахыры 2 нче биттә >

БЕР ГАСЫРЛЫК ГОМЕР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Ник кешеләрне сөендермәскә әле! Язмыш миңа бәхетле картлык бирде, – дип сөйләгән иде тормыш үзәгендә кайнарга яратучы, активлыгы белән аерылып торучы әбекәй. Җыр-моң яратуы балаларына да, оныкларына да күчкән. Хәзер дә концертларга, төрле мәдәни чараларга йөри әле ул.

Ижауда кызларында кунакта чакта концертларга бара. Салават Фәтхетдинов концертында иң өлкән тамашачы буларак халык артистының бүләгенә дә лаек булган. Салаватның: «100 яшеңә килә́м әле», – дигәнен хәтерендә тотып, аның килгәнен көтә. Йөзенче яше белән барганда, әбекәйнең кан басымы күтәрелде дип, «ашыгыч ярдәм» чакыралар. Фельдшерлар килгәннән соң, бергәләп аның бүлмәсенә керсәләр, әбекәй газета укып утыра икән.

Туган авылында улы Гафият һәм килене Фәния янәшәсендә гомер көзен каршылаучы әбекәйләрнең капкасын узган ел замана афәте – коронавирус эзләп тапты. Үзе дә, улы да авырдылар. Маһинур әби бу чиргә дә бирешмәде. Тик улы гына сихәтләнә алмады – 68 яшендә күзләрен мәңгегә йомды.

– Гафиятуллам бик матур көйләр яза, җырлый да, баянда да уйный иде. Аны юксынып, җырларын тыңлыйм, – дип, күз яшьләрен сөртеп ала, ә үзе кешеләргә рәхмәт укый. – Гомер-гомергә авылдашларым һәм җитәкчеләребез игътибарын тоеп яшим. Быелгы кышны кызым Гөлнур гаиләсендә Ижауда уздырдым. Район башлыгы Азат Вәлиев, анда килеп, 100 яшьлек юбилеем белән котлады. Россия Президенты Владимир Путинның, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның котлауларын да ирештерде. Ижау шәһәренең Ленин районы хакимиятеннән дә килделәр. Уразайга кайтып, кияү-киленнәрем, биш оныгым, унике оныкчыгым, туганнарым, дусларым җыелып, гомер бәйрәмемне зурлап бәйрәм иттек. Озын гомеремне мин Аллаһ бүләге дип уйлыйм. Раббыбыз мине бөтен нәселемә, күршеләремә, авылдашларыма догада булу өчен яшәтәдер. Барысына да дога кылам, теләк телим.

Асия КОРБАНГАЛИЕВА. Әгерҗе

«БУ ЯШЬКӘ ҖИТӘРМЕН ДИМӘГӘН ИДЕМ»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

1949 елда Киров ягына бер елга торф чыгарырга җибәрделәр. Кая кушсалар, шунда бара торган идек. Аннан кайткач, берничә елга Лаешка урман кисәргә җибәрделәр. Иптәш кызым белән ике тоткалы пычкы ярдәмендә утын кисә торган идек. 11 ел чамасы күчмә вагонда эшчеләргә аш пешереп, пешекче булып та хезмәт куйдым. Ә авылга әйләнеп кайткач, хезмәт юлымны колхозда дәвам иттердем. Үгез-таналар симертүдә, тавык-чебешләр үстерүдә эшләдем. Үз гомеремдә эшсез торган көнемне хәтерләмим.

Шәхси тормышына килгәндә, кияүгә чыкса да, тигезлектә яшәргә насыйп булмаган Гыйлембану апага. Яшьли бала белән ялгыз калып, кызы Әлфинурны берүзе тәрбияләп үстерә ул.

– Тормыш авыр булса да, зарланырга яратмадым. Үз хәләл көчебез белән яшәдек. Авыр чакларым бик күп булды. Инде алар арттa калды. Әлфинур кызымның өч кызы булды. Менә хәзер берсеннән-берсе матур 5 оныкчыгым үсеп килә. Тормышларыбыз, табыннарыбыз мул, – ди әбекәй.

Хәзерге көндә Гыйлембану әби кызы Әлфинур тәрбиясендә гомер итә. Үз тырышлыклары белән өйләренә ремонт ясап, каралты-кураларын яңартып, тормыш алып баралар. Аларның ишегалдына килеп керү белән, әкият иленә килеп эләккәндәй, гүзәллеккә юлыгасың. Аллы-гөлле чәчәкләргә төренгән, җиләк-җимешләргә күмелгән бакча үзе үк биредә тырыш, эш сөючән хуҗалар яшәгәнен күрсәтеп тора.

ХӘТЕР САНДЫГЫНДА ТАРИХ ЯШИ

Һәркем үзе бер тарих яза. Әлеге язмам – Мамадыш, Саба якларында туып-үсеп, кешелекнең барлык гүзәл сыйфатларына ия булган Илгиз Абдуллин хакында. Максатым – якташларыбызның аңа карата тирән ихтирамлы фикерләрен җиткерү иде.

Әтиләре Абдулла Бикмөхәммәт улы 1918 елда Саба районының Иске Икшермә авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Әтисенең бабаларыннан калган кәсебе каен тузыннан дегет ясап сату була, шунлыктан Үзәкәй Бикмөхәммәт гаиләсен яшь совет хөкүмәте хәерче һәм ярлы булмаган өчен өнәп бетерми. 1936 елда Лубян урман хуҗалыгы техникумына укырга кергәндә, документларын бераз үзгәртергә кирәк була. Әмма ике ай укуга, укучы иптәшләре әләкләве нәтиҗәсендә «кулак малае» исеме тагып, уку йортыннан куалар. Гыйлемгә тартылган егетне бу шомлы вакыйга гына туктатмый, яңа документлар ясатып, Мамадыш укытучылар техникумына укырга керә ул. Укытучылар җитмәгәнлектән, ул чорларда укучыларны читтән торып укуга күчереп, мөгаллим итеп мәктәпләргә җибәрәләр. Шул вакытларда булачак тормыш иптәше – Югары Ушма кызы Зәйтүнә белән таныша. Уку чорында алар районыбызның төрле мәктәпләрендә укытып, 1938 елда гаилә коралар.

Яшь гаиләне Кече Кирмән авылына эшкә җибәрәләр. Шунда беренче уллары Венер туа, ул озак яшәми – каты авырудан үлеп китә. Бер елдан Абдулла белән Зәйтүнә Арташ авылына юллана, анда икенче балалары, язмамның сәбәпчесе Илгиз туа. Язмыш дими ни дисең, бу гаиләне яңадан икенче авылга – Яңа Комазан башлангыч мәктәбенә җитәкче итеп җибәрәләр. Гаилә башлыгының күптәнге теләге үз якларына, Сабага кайтып төпләнү булса да, аларга ниятләрен тормышка ашыру бары 1951 елда гына насыйп була. Ул районда да гаиләгә Явлаштау, Сатыш, Мәртен авыллары мәктәпләрендә эшләргә туры килә.

Ниһаять, гаилә 1962 елда Иске Икшермәгә – Абдулла абыйның бабалары нигезенә кайтып төпләнә. Пуҗымны кире кайтару, кредитка йорт төзү, мәктәптә эш урыны табу җиңелләрдән булмый. Ничек итсә итәләр, тырышлыклары, уллары булышлыгы белән төп нигезгә яшәү

яме кертәләр. Мин бу юлларны нигә язып, искә алдым? Бер күчену бер янгынга тиң, диләр. Әгәр аңа ышансак, бу гаилә нинди генә авырлыклар, кайгы-хәсрәтләр күрмәгән. «Тормышта яшәү өчен, кеше булып калу өчен ачлык, хәерчелекнең үзәгеннән узмаган булса, балалары яшәүдә, укуда, олы мәхәббәттә зур уңышка ирешә алырлар иде микән?» дигән сорау туа.

Әйе, гаилә зурая, исән калган балаларның сигезе дә югары белем ала. Алар химиклар, укытучылар, табиблар булып, тормышта үз урыннарын табып, халкыбызга игелекле хезмәт итәләр. Һәр гаиләдә юл ярып, башкаларын үз канаты астына җыеп, әйдәп баручы була. Монда андый кеше олы абыйлары Илгиз була. Мондый гаилә балалары арасында бер-береңне зурлау, хөрмәтләү, әти-әнигә булган кадер-хөрмәт, туган-үскән җиргә мәхәббәт бермә-бер көчлерәк, ягымлырак була. Бу – хакыйкать.

Алга таба Илгиз Абдулловичның биографиясен ачыклап язу теләге булмаса да, аерым мизгел-хатирәләргә тукталып үтәсе килә. Өлгергәнлек аттестатын Саба урта мәктәбеннән ала, берничә ай укытучы булып эшләп, дүрт ел Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1969 елда Казан дәүләт педагогика институтының тарих бүлеген Ленин стипендиаты булып тәмамлый. Укыганда, Казахстанда чирәм җирләрне үзләштерүдә отряд командиры, студсовет рәисе, институтның 5 нче санлы уку бинасы комитеты (оешмасы) җитәкчесе булган өметле яшь белгечне 1974 елда институт ректорының административ-хуҗалык эшләре буенча урынбасары итеп билгеләп. Проректор Илгиз Абдуллин, югары уку йортының укыту-матди базасын, хезмәткәрләрнең һәм студентларның яшәү-көнкүреш якларын яхшырту өчен, фидакарь хезмәт куя. Ул шушы тынгысыз хезмәтендә 35 елдан артык эшли. Хезмәт биографиясен җитмеш яшеннән соң да эшләп, студентларның Универсиада авылы биләмәләрендә җитәкче вазыйфасында тәмамлады.

Һәр җирдә, илдә югары уку йортларының алтын баганасы булып дәүләт университетлары һәм педагогика институтлары санала. Бөтен гомерен институтта проректор вазыйфасын намуслы башкарган итагатьле, игелекле, меңнәрчә студентларга икенче әти булган шәхесебезгә август аенда 80 яшь тулды.

Мин язмам героеның хезмәт уңышларын, хөкүмәт бүләкләрен санап үтүне максат итеп куймадым, ә алар бик күп. Ничек аз булсын: тынгысыз, борчулы хезмәттә 35 елдан артык эшләгәндә ирешелгән уңышлар әйтеп тә, язып та бетергесез.

Әниләре Зәйтүнә Вәгыйз кызы гомер буе үзенең сагышларын, кичерешләрен шигъри дүртьюллыкка салып, «Сагыну җырлары» язып бара. Ул шигырь юллары, гомер юлларына үрелеп, хәтер сандыгында урын ала. Ә анда тарих яши! Әти-әниләренең балаларга васыять иткән горур тарихы яши.

Хәлим СӘЛАХОВ. Мамадыш

АКСАКАЛ

«99 ЕЛ 9 КӨН КЕБЕК КЕНӘ ҮТКӘН», – ДИ ЗИННӘТ БАБАЙ

Шәмбалыкчы авылында гомер итүче сугыш һәм хезмәт ветераны Зиннәт ага Хәйруллин 99 яшьлек гомер бәйрәмен каршылады.

Зиннәт бабайның хәтеренә, камил акылына, төгәллегенә сокланырлык. Аның һәр җөмләсе төзек, мәгънәле һәм тулы. Вакыйгалар, мәгълүматлар төгәл, ачык, аңлаешлы. Тормышны сөеп, яратып, һәр көненнән тәм табып яши ул. Уллары, оныклары аны кайгыртып кына тора. Кышларны Казанда уздырса да, авылда ул – үз һәм хөрмәтле кеше. Туган көне белән котлаучылар да күп булды ветеранны. Район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гөлүсә Галләмова район башлыгының котлауларын ирештерде.

– Тормышта тирән эз калдырган, ут-сулар кичкән аксакал сез! Яшьләргә бар яктан да үрнәк булып торасыз. Тагын да олы гомер бәйрәмегезне каршыларга язсын, – диде ул.

Зиннәт бабай 1941 елның август аенда армиягә юл ала. Мәскәү, Калуга, Смоленск, Брянск өлкәләрендә, Белоруссия, Польша җирендәге бәрелешләрдә катнаша, Кенигсбергны азат итү вакыйгасының шаһиты була.

– Бик авыр, катлаулы юл үттек. Кырда урак урганда, сугыш башлану хәбәре таралды. Илебез азатлыгы өчен гомеребезне дә кызганмадык. Яшьләр дә Ватанны яратсыннар, хезмәт сөючән булсыннар иде, – ди ветеран.

Озак еллар дәвамында яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә зур өлеш керткән шәхес ул. РСФСРның Мәгариф отличнигы, «Татарстан Республикасының атказанган укытучысы» исеменә лаек булган.

Тынгысыз күңелле, мәдәниятне, сәнгатьне үз иткән Зиннәт бабай Фәхри Насретдинов һәм Бану Вәлиева музеен оештыруга зур өлеш керткән. 20 елга якын музейны җитәкләгән. Хезмәт елларында күп кенә республикакүләм фәнни-гамәли конференцияләрдә, бәйгеләрдә катнашкан. Күңеле тулып ташыганда, кулына каләм ала. Ул – район газетасының һәм республика басмаларының актив хәбәрчесе дә.

– Матур гомер юлы уздым. Бер минутны да әрәм үткәрмәскә тырыштым. Хезмәтем тынгысыз булса да, нәтиҗәле булды. 99 ел 9 көн кебек кенә узган да киткән, – ди аксакал.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА.
Апас районы

Сагышларга уралган мизгелләр

Апаста яшәүче Рәшидә әби Хөсәенова 90 яшьлек юбилеен билгеләп узды. Олы юбилее уңаеннан, акъәбигә Ил башлыгының котлау хаты, район башлыгының котлау открыткасы тапшырылды. Район Советы аппараты җитәкчесе Ринат Гыйльфанов, акъбине тәбрикләп, изге теләкләрен юллады.

Көр күңел белән каршылады Рәшидә әби үзенең олы гомер бәйрәмен. Авыр хезмәт йөген тарткан, язмыш сынаулары, ачы бала хәсрәтләре кичергән акъәби гомер күзләрендә дә сынмаска, сыгылмаска тырыша.

Һәр якты көнгә сөенеп яши, ямь таба. Бакчасында яшелчә, җиләк-җимеш гөрләп үсә, ишегалдында кош-корт йөгерә. Ул аларга күңел җылысын өләшә, назлап тәрбияли. Озын кичләрне кулына энә белән җеп алып, урындыкларга япмалар, бизәкләр бәйли.

– Аллага шөкер, яшим, дип гомер итәм. Хәрәкәттә булырга тырышам. Янәшә йортта гына кызым Мәдинә яши. Ул һәрчак минем белән, – дип сөенә акъәби.

Сагышларга уралган мизгелләрдә Рәшидә әби шигырьләр дә иҗат итә. Үзенең үткәннәрен, балачак мизгелләрен, күңелендәге борчу-сагышларын да ак кәгазь битләренә төшерә ул.

Без бәхетле бала булсак,
Сугышлар булмас иде.
Әтиләрне алып китеп,
Ятим итмәсләр иде.

Рәшидә әби Хөсәенова бүген дә хәрәкәттә булырга тырыша.

Шахталарда чыгаралар
Таш дигән күмерләрне.
Ач, ялангач, нужа белән
Үткәрдек гомерләрне.

Балаларымны югалттым.
Бер-бер артлы киттеләр.
Минем калган гомеремне
Караңгы төн иттеләр.

Без картайдык, әнкәйләр юк,
Киттеләр рәхәт күрми...
Алар яшәгәнен уйлап,
Йөрәккәйләрем әрни.

Рәшидә әби Хөсәенова Дүртиле авылында туып-үсә. Ул икенче сыйныфта укыганда, әтисен сугышка алалар. Йорт тоткасыз кала. Гаиләне тоту, ашату нәни кызчыкның җилкәсенә дә төшә. Колхозда төрле эшләрдә эшли. 16 яшендә Пүчинкәгә кирпеч заводына эшкә китә. Анда ике ел эшләгәннән соң, Кемерово өлкәсенә торф чыгарырга бара. Бик күп тапкыр урман кисү эшендә дә катнаша.

– 5 ел торф казуда эшләдем. 4 ел Ярославльдә булдым. Кыш көне урман кисә идек. Аннан кайткач, колхозда эшләдек. Май аенда киттек. Октябрьдә кайттык. Гомеремнең бер минуты да эшсез узмагандыр, – ди ул.

Рәшидә әби, гаилә корып, 4 балага гомер бүләк итә. Тик, кызганыч, ул өчесен бер-бер артлы соңгы юлга озата. Бүген ул кызы Мәдинә һәм оныклары тәрбиясендә гомер кичерә. Күңелендәге борчу-сагышларны да шөгыль, хезмәт белән басарга тырыша. Тәмле ризыклары белән сыйлый, уңганлыгы, тырышлыгы, тормышны яратуы белән сокландыра.

Ләлә САФИУЛЛИНА. Апас районы

Сугыш көйдергән язмыш

Апаста гомер итүче Ләлә әби Шәйдуллина гөлләр, чәчәкләр белән сөйләшеп, аларның барчасының файдасын, үзенчәлеген аңлап, тормыштан тәм табып яши. Гел хәрәкәттә булырга, йорттагы вак-төяк хезмәтләрне дә тизрәк үзе эшләп куярга тырыша. Яхшы кәеф, көр күңел белән, тормышның рәхәтен тоеп гомер итәргә тели ул. Күңеленә авырлыклары белән кереп калган балачак, яшьлек еллары аны бүгенгенең кадерен белергә өйрәткән.

Ләлә әби гомерендә ачлыгын, юклыгын да татыган, кыенлыкларны йөрәгә аша уздырган.

– Яшьлегем булмады да, хәсрәт эчендә үстек. Сугыш башланганда, миңа 11 яшь иде. Әти яуга китте. Йортларыбыз иске иде. Мәктәптән эшкә җибәрделәр. Фермада сыерларга, атларга салам турадык. Безнең якларда окоп казыган елларда кечкенә генә йортыбызда 13 кеше торды. Ашарга да, ягарга да, йокларга, утырырга урын да юк иде, – дип искә ала Ләлә әби. – Нужаларны күп күрдек. Кырга башак җыярга чыгаралар иде. Аякта, өстә юк килеш эшләдек. Аяк бармакларымны ике тапкыр өшеттем. Хәзер тормыш бик рәхәт, яшәгән саен яшисе килә.

Мәктәптән соң укуын дәвам иттерү мөмкин булмый Ләләгә. Әтиләре дә яу кырында һәлак була. Гаиләдә 6 бала. Хезмәт юлын ул 15 яшендә Чапаев исемендәге колхозда башлап җибәрә. Хисапчы ярдәмчесе булып билгеләнә. Аннан 1944 елда районның финанс бүлегендә эшли башлый. Тынгысыз хисапчы эшеннән тыш, комсомол, профсоюз секретаре, судта халык утырышчысы да була. Биредә озак еллар хезмәт итә. Аннан Госстрахта баш бухгалтер вазыйфасын башкара. Макталып, данланып эшли ул.

Апас егете Фатыйхка кияүгә чыга. 3 балага гомер бүләк итеп, аларны үстереп, барысына да югары белем бирәләр. Кызганыч, борчу-кайгылар да күп килә. Баштa ире вафат була, язмыш аны бала хәсрәтләре белән дә сыный. Бүген ул кызлары, оныклары, оныкчыклары белән горурланыен яшерми.

– Кызларым янымнан да китми. Аллага шөкер, хасияттә, хөрмәттә акъәби булып яшим. Кадерләп торганга, 95кә җиттем инде, – ди Ләлә әби.

Кызлары Әлфия һәм Лилия, укытучылар нәселен дәвам иттереп, Апас мәктәбендә укучыларга белем һәм тәрбия бирәләр. Әниләре белән киңәшеп, серләшеп яшиләр.

– Әнинең хәтере бик әйбәт. Үткәннәрне түкми-чәчми хәтерли. Күп вакыт бергә утырып, хатирәләр яңартабыз. Кечкенә вакытта бергә җыелышып утырган чаклар да искә төшә. Әниебезнең язмышы җиңел булмаган. Тормышны үз җилкәсендә алып бара ул. Без аның белән горурланабыз, яныбызда булганга шатланабыз, – диләр Ләлә әбинең кызлары Әлфия белән Лилия.

БӘХЕТЕ БЕЛӘН КИЛСЕН

«Барган урыныңда таш бул...» Белмим, хәзерге әти-әниләр, кызларын кияүгә биргәндә, мондый сүзләрне әйтә беләмикән? Заманалар үзгәргән бер чорда аның әһәмиятен аңлап кабул итүчеләр, бәлки, юктыр да. Ничек инде таш бул? Бәлки матуррак, йомшаграк итеп әйтү кирәктер. Әле кем ничек кабул итә бит? Ә бу сүзләр бик тирән мәгънәгә ия. Аны бары тик гомер юлының күп елын бергә узганнар гына аңлый аладыр, мөгаен.

Әтнә үзәк китапханәсендә «Килен төшә бүген авылга» исеме астында узган бик матур, эчтәлекле чара да нәкъ әнә шул сүзләрнең мәгънәсе турында иде. Кыз сорау, никах көне, туй йолалары, туй бирнәсе – халкыбызның әнә шуларга бәйле күпме матур гореф-гадәтләре бар икән бит! Элегрәк ничек булган, хәзер дә сакланамы бу йолалар, безнең районда ничек тә күршеләрдә ничек – чакырылган кунаклар белән әнә шул хакта фикер алыштык, башкаларны тыңладык, үзебезнең тормышта булганнар белән уртаклаштык. Арада биш дистә елга кадәр матур гына гомер кичереп, үрнәк булган гаилә тоткасы ханымнар да, әле яңа гына парлы тормышка аяк басучылар да бар иде. Очрашуны, бик мәгънәле һәм кызыклы итеп, китапханәнең әйдәп баручы белгече, үз эшенең остасы Гөлнур Шәйхетдинова алып барды.

Табын түрендә – Каенсар авылыннан, өлкән яшьтә булуына карамастан, бик әзләнүчән кеше Сөембикә апа Мәгъсүмҗанова. 51 ел тормыш иптәше белән иңне иңгә куеп тормыш иткән ул. Шуңа да аның яшьләргә әйтер сүзләре үтемле. Үзе яшәгән чорда гаилә корунын бөтен нечкәлекләрен хәтерли. «Безнең өчен өлкәннәр сүзе бик мөһим булды. Әти-әни әйткәннән чыкмадык, аларны борчудан бик курыктык. Тормыш иптәшем белән, Аллага шөкер, алдан очрашып табышмасак та, бик матур яшәдек. Насыйбым шушы дип кабул иттем ул чакта, алты балага гомер бирдек», – ди ул.

– Кыз сорарга килгәндә, башта әти каршы булды, – дип искә ала Олы Мәңгәр авылыннан Хәлимә апа Закирова. – Әмма кияү ягыннан килгән «мөхтәрәм делегация» үз сүзен сүз итте, әтинең ризалыгын бирми хәл булмады. Ул заманның бөтен шартларына туры китереп, борынгы йола буенча, никах мәҗлесе үткәрдек. Иң көтелмәгәне туй көнне Мәңгәр башына кайтып җиткәч булды. Биредә безне бик матур итеп бизәлгән атлы тарантас көтеп тора иде. Аны бизәү өчен бөтен нәрсәне, ике ул оныгына әманәт итеп, тормыш иптәшемнең бабасы Закир алдан ук әзерләп куйган булган. Кучер, гармунчы һәм булачак ирем белән без шул тарантаста урам әйләндек. Ул чакта бик оялсам да, хәзер инде бу – безнең өчен гомерлек истәлек.

Балтач, Саба якларыннан килгән киленнәр исә үз якларында булган туй йолалары турында сөйләде. Зилә Шәфигуллина, Райлә Галиеваның хатирәләре безнең яклардагы белән аваздаш булып чыкты.

Китапханәчеләр чарага әзерлек кысасында төрле чорда модада булган туй күлмәкләреннән күргәзмә дә ясаганнар. Алар арасында иң кызыклы экспонат 76 ел элек Германиядән кайткан ак күлмәк булгандыр. Аны Сибгат Хәким исемендәге музей директоры Гөлсинә апа Хәкимуллинаның бабасы сугыштан кызына дип алып кайткан. «Әни бу күлмәкне туйга киде микән, белмим, әмма бик яратып киюе турында гел әйтә иде», – ди ул. Югары сыйфатлы материалдан тегелгәнгәдер, әлеге көндә дә бик яхшы хәлдә сакланган күлмәк. Гөлсинә апаның, укытучы Илсөя апа Габидуллинаның, акушерка Халидә апа Хәбибуллинаның, «Туган якны өйрәнү» музее хезмәткәрләренең туй күлмәкләре дә бик үзенчәлекле иде.

Бәйрәмнең тагын бер кунагы Күлле Киме авылыннан Ирина Хәмидуллина иде. Ирина күрше Мари Иленнән килен булып төшкән. Аның әти-әниләре баштарак татар егетенә чыгуына каршы булган, чөнки икесе ике диндә. Ирина үзе, тормышка чыккач, ислам диненә күчкән һәм моңа бер дә үкенми. Якыннары да аның бу гамәлен аңлап һәм хуплап кабул иткән.

Күп нәрсәләр хакында сөйләштек очрашу барышында. Килен сандыгы хакында танылган шагыйрә Гөлүсә Батталованың хатирәләре дә, шул ук Гөлсинә Хәкимуллинаның кызыклы чыгышы да бик эчтәлекле иде. Очрашуга сыйныф җитәкчесе Гөлара Хәбибуллина белән берләктә Олы Әтнә урта мәктәбенең унынчы сыйныф укучылары да чакырылган иде. Моның да үз мәгънәсе бар: яшьләр дә бит кайчан да булса килен булып төшәсе. Бик дикъкать белән тыңлап утырдылар, кызларга кичә шулай ук бик ошагандыр дип ышанам. Бу йолалар онытылмасын иде.

Фәридә ФИЛАТОВА.
Әтнә

МИН ТОРМЫШКА ГАШЫЙК

Кушлавыч клубында «Мин тормышка гашыйк» дигән әдәби-музыкаль кичә үтте. Анда районыбызның өлкән яшьтәге талантлы шәхесләре катнашты.

Зур булмаган авылдагы кечкенә, иске генә клуб гөрләп тора. Озак еллар эшләгән атказанган мәдәният хезмәткәре Фәния Хәнәфиева турында тынгысыз җан дияргә була. Чираттагы ялда булуына карамастан, җәйге эш өстендә дә ул, чара оештырып, авылдашларының күңелләрен күрә. Кырык эшен кырык якка ташлап, клубка очрашуга килгәннәр бит.

Күптәннән хыялланып йөрде инде Фәния бу чараны оештырырга. Әле берсенең, әле икенчесенең җае булмады. Ахыр чиктә, район ветераннар оешмасы җитәкчесе Рәмзия Хәмидуллина ярдәмендә дә туплап алып килде.

«Каурый каләм» иҗат берләшмәсе әгъзалары Марсель Шәрәпов, Факия Шәрәфетдинова, Халидә Вафинаны, заманында бергә эшләп, аларны үзенең остазлары дип санаган Роза Шәйхетдинова белән Равил Габдрахмановны чакырган ул.

«Нәрсә соң ул – тәмле әйбер?»

Фәния Хәнәфиева сүзне беренче остазы Роза Шәйхетдиноваga бирде. Кыскача гына аның тормыш юлы белән таныштырып үтте.

– Роза апа, «Ак ефәк шәл» исемле шигырегез шигърият сөючеләр тарафыннан җылы кабул ителде. Нәрсәне күз алдында тотып яздыгыз сез аны?

– Сугыш елларын. Авыр вакытлар. Ашарга-эчәргә юк. Мин авырып ятам. «Әз генә тәмле әйбер булса, мин тазарыр идем», – дим әнигә. Әни түзмәде, өйдән чыгып китте. Бераздан кайтты да умачлы аш пешереп ашатты, берничә кашык он белән бәрәңгедән кабартма кебек әйбер ясады. Каян алганын соңыннан күз яшьләре белән әйтеп торуын ишетеп аңладым. «Һай, шул шәлне сатмаган булсам...» – диде ул. «Әни, үскәч, мин сине тәмле әйберләр белән сыйлармын», – дим. «Нәрсә соң ул – тәмле әйбер?» – дип сорый әни. «Ипи. Аннан мин сиңа ак ефәк шәл алып бирермен», – дим. Озак эзләдем мин ул шәлне. Тик... таба алмадым. Ә тапканда, әни юк иде инде. Укытучыма бүләк иттем. Әнигә булмаса да, вәгъдәмне үти алуыма сөендем, – диде Роза Шәйхетдинова.

– Кем өчендер шигырь – сүзләр генә, минем өчен шигырь – таяныч, – диде ул һәм шигырьләрен укыды, истәлеккә китабын бүләк итте.

Гаҗәеп кеше

Алып баручы сүзне милиция майоры Марсель Шәрәповка бирде. Лаеклы ялга чыккач, клубка урнашты. Ә шигырьләрен кайчан яза башлаган? Үзенчәлекле, эчтәлекле, матур аның шигырьләре.

– Кечкенә чакта да, мәктәп елларында да язгаладым. Тик язган берсен ертып ташлап бардым. Отставкага чыккач, ныклап тотындым. Социаль челтәрләргә куйдым. Халык күтәреп алды. Шуннан китте инде, – диде Марсель Шәрәпов.

Шигырьләре генә түгел, район газетасында участок инспекторы язмалары да чыкты, пьесасы да сәхнәгә куелды. Ике китабы басылды. Күпкырлы талант иясе ул. Иренми, нинди чарага чакырмасыннар, гармунын күтәрә дә чыгып китә, шигырьләрен укый, үзе уйнап җырлый. Кул эше остасы да. Электр бишегенә кадәр ясаган.

«Мин янып-көеп яшим»

Кичәне «Тик үземчә язйым әле, калыйм әле үзем булып», «Мин янып-көеп яшим, пыскып ятмыйм мин, яшим», «Ялкынланып яшәүләрдә бар кызыгы дөньяның» дигән шигырь юллары авторы Факия Шәрәфетдинова дәвам итте.

ИГЕЛЕКЛЕ ҺӘМ МӘРХӘМӘТЛЕ ЭШ

Узган елда Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасының «Прокат добра и милосердия» проекты Татарстан Икътисад министрлыгының социаль әһәмиятле проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциясез оешмалар өчен грантын отты.

Республика ветераннары (пенсионерлары) советы, проект чараларын тормышка ашыру кысасында, техник реабилитация әйберләре сатып алды.

Техник реабилитация чараларының (ТСР) чирдән соң кешене тергезүдәге әһәмияте гаять зур. Проект сәламәтлеге какшап киткән, әмма шәхси реабилитация программасына ия булмаган өлкәннәргә, шулай ук җәрәхәтләнү-имгәнү, каты авыру сәбәпле, авыр хәлдә калучыларга бүлмәдә һәм урамда йөри торган коляскаларны, култык таяклары, телескопик таяклар, «Алмаг 001» магнит терапиясе аппараты, тәнне бозмый торган матраслар, шудырма җәймәләрне һ.б. прокатка бушлай алып тору мөмкинлеге бирә.

Республика советы бу юнәлештә зур эш тәҗрибәсенә ия. Әлеге проект 2012 һәм 2018 елларда Татарстан Министрлар Кабинеты грантын откан проектыбызның дәвамы булып тора. Бу грант акчасына 129 данә медицина җиһазы (инвалидлар өчен кресло-коляскалар, култык таяклары, глюкометрлар) сатып алынып, техник реабилитация чараларына мохтаҗ өлкәннәрне тәэмин итү өчен, республиканың 10 районына тапшырылды. 2018–2020 еллар чорында әлеге медицина җиһазларыннан 250гә якын кеше файдаланды.

Түләүле патронаж хезмәтләре күп кенә шәһәр-районнарда юк. Булса да, техник реабилитация чаралары прокатка түләүле нигездә генә бирелә. Ә өлкәннәрнең күбесе моңа акча таба алмаска да мөмкин.

Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасына (өлкән яшьтәге 980 меңнән артыграк активистны берләштерә), тормышта авыр хәлдә калган өлкәннәрдән, инвалидлардан медицина җиһазларын сатып алуда яки алар белән вакытлыча тәэмин итүдә ярдәм сорап, һәр ел саен 150дән артыграк мөрәҗәгать алына.

Республика ветераннары советы техник тернәкләндерү чараларын, прокат һәм кабул итү-тапшыру акты килешүен төзү нигезендә, тапшырылган гариза буенча бушлай бирә. Проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә агымдагы елның 1 гыйнварыннан 30 июньгә кадәр 30 кешегә медицина җиһазлары белән тәэмин итү рәвешендә ярдәм күрсәтелде инде.

Шул рәвешле өлкәннәр кыйммәтле җиһазларга акча исраф итүдән котыла. Соң, аны билгеле бер вакытка бушлай гына алып торырга мөмкин бит. Акчаны янга калдыру гына түгел, савыкканнан соң җиһазны сату-урнаштыру проблемасыннан да коткара әле бу.

Әйтергә кирәк, безнең проект техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү буенча дәүләт программасын алыштырмый. Реабилитация һәм инвалидлык алу өчен кирәкле документлар рәсмиләштерү чорында әлеге хезмәтне өстәмә күрсәтү мөмкинлеге бирә ул.

Республика ветераннары (пенсионерлары) советы өлкәннәрне яки аларның туганнарын техник реабилитация чараларыннан файдаланырга өйрәтү буенча Казан халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге белән килешеп эшли.

ТСР прокаты пункты ярдәмгә мохтаҗ өлкәннәрнең тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән. Проектның максаты – җәрәхәтләнү-имгәнү, каты авыру сәбәпле, тормышта авыр хәлләрдә калган өлкәннәргә, техник реабилитация чараларына вакытлыча мохтаҗ булучыларга ярдәм кулы сузу.

Моннан тыш узган елның сентябрендә Республика ветераннары (пенсионерлары) советы инвалидларга һәм сәламәтлеге какшаган өлкәннәргә ваннада, душта юыну өчен «Титан-450» дигән 17 урындыкны бушлай файдалануга тапшырды. Бу урындыклар «Россия Кызыл Хач» Гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстандагы төбәк бүлегеннән хәйрия рәвешендә алынган иде.

Кыскасы, «Прокат добра и милосердия» проекты инвалидлар һәм пенсионерларга ярдәм итү, өлкәннәрнең тормышын җиңеләйтүне иң зур максат итеп куя.

Татьяна САБЕРҖАНОВА,
Республика ветераннары (пенсионерлары) оешмасының
Сугыш ветераннары белән эшләү һәм аларның истәлеген
мәңгеләштерү буенча комиссиясе рәисе

– Башта артист буласым килгән иде. Энем авырды. Медицина хезмәткәре булу, кешеләрне дәвалау теләге туды. Гомеремне шул һөнәргә багышладым. Җырлавымны да ташламадым, сәхнәләрдән төшмәдем, – диде ул. – Әтиәниемә рәхмәтлемен. 9 балалы гаиләдә 6 нчы бала булдым. Кеше итеп үстерделәр. Хезмәтемнән тәм һәм ямь табып яшәдем, – диде ул.

Факия Шәрәфетдинова да шигырьләр иҗат итә, китаплар авторы. Кичәдә шигырьләрен генә укып калмады, тамашачыларга яраткан җырларын да бүләк итте.

Кунакларның барысы да талантларын күрсәттеләр. Гомерен мәгариф өлкәсенә багышлаган Халидә Вафина сөенә-сөенә килгән. Чөнки тумышы белән шушы яктан, Югары Сәрдәдән. Әтисе яшьли вафат булып, әнисе дүрт бала белән ялгызы калган. Тырышкан, балаларын аякка бастырган. Әнисе Мөнирә апа бик матур җырлаган, бу сәләте кызы Халидәгә дә күчкән. Искиткеч матур, моңлы аның тавышы. Шигырьләр дә иҗат итә Халидә ханым.

– Ниндидер зур проблемалар күтәрмим мин. Үз язмышым, гаиләм турында язам. Сәхнәләрдән җырлыйм. Шулар минем күңелгә рәхәтлек бирә, – диде ул. – Бу кичәгә чакырып, туган ягым кешеләре белән очраштырган өчен бик рәхмәтлемен.

Ул да очрашуга килгән туганнарына, авылдашларына багышлап, яраткан җырларын башкарды. Гомумән, чара җырлар, биюләр белән үрелеп барды. Авыл үзешчәннәре дә музыкаль бүләкләр әзерләгән иде.

«Бөтен үзешчәннәрне сагынам»

Соңыннан сәхнәгә заманында сәхнәләрне дер селкетеп биегән, моңлы тавышы белән бик күпләрне сокландырган, гомере буе мәдәният өлкәсендә эшләгән Равил Габдрахманов күтәрелде.

– Сәнгать җитәкчесе булып эшләгән чорларны сагынмыйсызмы? – дип сорады аннан Фәния Хәнәфиева.

– Районндагы бөтен үзешчәннәрне сагынам. Һәрберсе күз алдымда, – диде ул һәм кыскача гына үзе белән таныштырып үтте, яшьлек елларын искә төшерде. – Әти, биш баланы калдырып, әнине ташлап чыгып китте. Укуны тәмамлау белән, әнигә ярдәм итү максатыннан, Кышкар клубына мөдир булып урнаштым. Менә шуннан мәдәният дөньясына кереп киттем. Ә җырга килгәндә… 4 нче

сыйныфта укыган вакыттан бирле җырлыйм инде мин.

– Ни өчен җырчы булып китмәдегез?

– Арттан йөрүче булмады. Әмма җырлаудан туктамадым. Халык яратты, радиодан җырларымны көнгә егермешәр тапкыр җырлаталар иде, – дип җавап бирде Равил абый һәм үзенең хитка әверелгән «Зәңгәр чәчәк», «Ялгыз җилкән» җырларын башкарды.

Күңелгә үтеп керерлек матур чара булды бу. Тамашачылар да җылы каршы алды. Рәхәтләнеп ял иттеләр, дип алар исеменнән әйтсәм дә ялгышмамдыр.

Гөлсинә ЗӘКИЕВА. Арча

ЯРМИНКӘДӘ ОЧРАШУ

Күптән түгел Республика ветераннары (пенсионерлары) советының төрле җирлектәге оешмалары Алабугада Бөтенроссия Спас ярминкәсендә катнашты. Бирегә 13 районнан 50дән артык өлкән яшьтәге кул остасы үзләре ясаган эшләнмәләрне алып килгән.

Өлкәннәр яхшы кәеф тә өләште. Алар килгән кунакларга үзләренең җырларын, биюләрен бүләк итте. Беркем дә битараф калмады. Арча районыннан килгән осталар кунакларга истәлеккә милли бизәкләр белән чигелгән түбәтәй бүләк итте. Алар арасында Алабуга, Менделеевск районы җитәкчеләре, Беларусь Республикасының Татарстандагы вәкиле Виктор Щетько, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры Гөлзада Руденко бар иде. Татарстан ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштиряков кунакларга республикада өлкән буын вәкилләренең мәнфәгатьләрен кайгыртып гамәлгә ашырыла торган социаль проектлар турында сөйләде. Ә ветераннар үзләре исә, ярминкә эшендә актив катнашканнары өчен, дипломнар белән кайтып китте.

Сүз уңаеннан, республиканың ветераннар советы өлкән буынның сәләтен, булганлыгын, мөмкинлекләрен күрсәтү өчен шартлар тудыруга аерым игътибар бирә. Бу эш бигрәк тә пандемия елында, 2020 елда активлашып китте. Өлкәннәр үз белгәннәрен оныкларына да өйрәтәләр. Республика ветераннар советы осталар эшләре белән альбомнар чыгарды, алар турында «Когда поет душа» фильмын төзеде, халык иҗатының республика бәйгесен үздырды. Бүген ветераннар төрле күргәзмәләр һәм халык иҗаты ярминкәләре эшендә актив катнаша, балалар, шул исәптән социаль учреждениеләрдә яшәүчеләр өчен мастер-класслар үткәрә.

Шигърият

СОЛДАТКА

Ничә еллар мени салкын кышта
Ил сагында уяу торасың.
Җылы өйдә җылытасым килә,
Өшисеңдер, солдат туганым.

Кулларыңа кагылып, күләгәгә
Чакырасым сине килсә дә,
Һәйкәл-солдат, юк, кузгала алмый,
Тирләсә дә эссе челләдә!

Атна буе тоташ яңгыр яуды,
Ул чиләкләп коя бүген дә.
Ә плащың көтеп ята сине
Чит туфракта окоп төбендә.

Җиңү бәйрәмендә ватандашлар
Хөрмәт белән сиңа күз ата.
Толлар ире чалымнарын эзли,
Сөйгән ярга кемдер охшата...

Илгә Җиңү алып кайткан солдат,
Хәтерләрдә мәңге яшәрсең.
Чәчәк бәйләмнәре салган мәлдә
«Рәхмәт!» – диеп, гүя дәшәсең.

Алтмыш җиде ел
мени салкын кышта
Ил сагында уяу торасың.
Өйгә кайтыйк, җылытасым килә,
Өшисеңдер, солдат туганым!..

Таһир ШӘМСУАРОВ.
21.11.2020

ГОРУРЛАН

(Татарстан көнөнә багышлап)

Татарстан –
минем туган җирем,
Нинди матур Чатыр-тауларың.
Дөньядагы шушы гүзәллекне
Синдә яшәгәнгә аңладым.

Урманнарың синең, чишмәләрең,
Басу-кырлар, зәңгәр күлләрең.
Күпме яшәсәм дә, моның кадәр
Башка матурлыкны күрмәдем.

Горурланам Тукайларың белән,
Мәңге сүнмәс утың, Казаным.
Чит илләргә кадәр таралды бит,
Җиңүләрне яулый «КамАЗ»ың.

Иң тырышлар бары синдә генә:
Җитештерә «кара алтын»ын.
Яуда калган Алиш, Җәлилләрең –
Горурлыгы татар халкының.

Башка чит җир
миңа кирәк түгел,
Язмышымны сиңа бәйләдем.
Данын көн дә әйтеп, җырын суза
Салаватың, Ришат, Зәйнәбең.

Еракларга тавышларын илткән
Татар иле, ул – синең даның.
Халык йөрәгендә мәңге сүнмәс
Әлфия апа, Зиннур, Илһамың.

Мин сөенәм, яшә, Татарстан,
Алга атла барыр юлыңнан.
Тыныч тормышларда яшәгәнгә,
Минтимерең белән горурлан.

Газинур ӘХМӘТҖАНОВ.
Азнакай шәһәре.
2022

«БЕЗ ОНЫТСАК, БЕЗНЕ ДӘ ОНЫТЫРЛАР»

Моннан берничә көн элек Биектау мәдәният йортында Габдрәхим Мортазинны искә алдылар. Аңарчы шундый ук чара туган авылы Мүлмәдә үткәрелгән иде. Каберенә таш куелды. Бу көннәрдә аңа 95 яшь тулган булыр иде. Фани дөньяда 94 ел да өч ай гомер итеп, үзеннән бик матур, якты эз калдырды, былтыр декабрь аенда бакыйлыкка күчте.

Мортаза улы Габдерәхим бөтен тормышын, эшчәнлеген туган төбәген үстерүгә багышлады. 1965 елда Биектау мөстәкыйль район булarak оешканнан соң, район дилбегәсе чирек гасыр аның кулында була. КПСС райкомының Беренче секретаре вазыйфасында ул бөтен тырышлыгын, тупланган тәҗрибәсен эшкә җигә, район күзгә күренеп тернәкләнә, алдынгылар сафын тулыландыра. Игенчелек тә, терлекчелек тә бер үк дәрәҗәдә үсеш ала, эшлекле җитәкче кадрлар туплана. Габдерәхим Мортазин эш кешесен күрә, аның хезмәтен тиешенчә бәяли белә. Искә алу чарасында катнашучылар да аның шушы сыйфатын телгә алдылар.

Заманында районда хуҗалык җитәкчесе, аннан РАПО җитәкчесе булган Рәфыйк Гыйльметдинов: «Ул шактый ук кырыс җитәкче иде, әмма берәүне дә нахакка рәнҗетмәде, сүзен өздереп, күңелгә үтәрлек, нәтиҗә ясарлык итеп әйтте. Кырыслыгы таләпчәнлек белән үрелеп барды, – дип хәтер яңартты. – Мин – хәзер намаз кешесе. Габдерәхим Мортаза улын догадан калдырганым юк».

Чыгыш ясаучылар: «Габдерәхим Мортазинга хас сыйфатлар – әти-әни тәрбиясе», – дигән нәтиҗәгә дә килде. Әтисе Мортаза ага утызынчы елларда колхозлар оештыруда башлап йөри, авылда промартель җитәкчесе, райпотребсоюз рәисе, авыл советы рәисе булып эшли. Әнисе гомере буе фермада сыерлар сава, үрдәкләр үстерә.

Габдерәхимнең үсмер чагы сугыш чорына туры килә. Сугыш башланганда, аңа 14 яшь була. «Сугыш чоры балалары кебек үк мин дә нинди эш кушсалар, шуны башкардым, сайлап, сайланып тору заманы түгел иде, – дип искә ала торган була ул чакларны. – Тормыш авырлыгы өйрәтте, тормыш авырлыгы үзгәртте».

1944 елда аны хәрби хезмәткә алалар, Төньяк флотта хезмәт итә, диңгез сугышларында катнашып, батырлык күрсәтә, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнүе дә юкка гына түгел. Алты ел хезмәт иткәннән соң туган якларына кайта һәм тыныч тормышта баш-аягы белән эшкә чума, белемен күтәрергә кирәклеге турында да онытмый.

Республика ветераннар Советы рәисе Хәбир Иштирәков менә шушындый искә алу чараларының бик үтемле һәм кирәкле чара булуына басым ясады, агросәнәгать комплексы ветераннары советы эшчәнлеген үрнәк итеп куйды. Әлбәттә инде, һәр эштә башлап йөрүчеләрнең булуы кирәк. Заманында Биектау районында берничә хуҗалыкта җитәкче вазыйфасында булган, республика кошчылык тармагын үстерүгә бинһая зур өлеш керткән ветеринария фәннәре докторы Марс Алиев хәзер инде агросәнәгать тармагы ветераннары белән эшләүдә көч-куәтен, сәләтен кызганмый. «Биектауда Россия, республика күләмендәге семинар-киңәшмәләр бик еш үткәрелде, Биектауның абруе һәрвакыт югары булды. Төзелеш киң колач белән алып барылды, зур күләмдә капитал салымнар үзләштерелде, – дип искә ала Марс Алиев. – Бу инде Габдерәхим абыйның тырышлыгы нәтиҗәсе иде, без аның белән даими элемтәдә булдык, ул тормыштан ямь табып, куанып-шатланып яшәде. Гаиләсе матур, үрнәк иде. Әминә апа һәрвакыт таяныч булды, балалары шушы үрнәктә үстеләр».

Биектау районы Башкарма комитеты җитәкчесе Равил Хисаметдинов искә алу чарасының тәрбияви әһәмиятkә ия булуын ассызыклады. «Бер генә изге гамәл дә тарихтан сызылып атылырга тиеш түгел. Ул – безнең байлыгыбыз, ул – безнең киләчәккә этәргеч. Үткәнне, шул чордагы шәхесләребезне онытсак, безне дә онытачаклар. Бу инде бик аяныч».

Әйе, вакыт дигәне сизми дә узып китә. Кеше язмышын үзгәртеп булмый, әмма аның турындагы хатирәләрне саклап, һәрдаим яктыртып бару – кулдан килә торган гамәл.

Лилия ХӘМИДУЛЛИНА,
китапханә хезмәткәре

Рәхмәтле тормыш

Тормышыбыз якты күңелле, җыр-моңга гашыйк кешеләрдән яктыра. Шундый күркәм кешеләрнең берсе – Биектау районының Чыршы авылында яшәүче үзешчән җырчы Фаягөл Хәмидуллина.

Питрәч районының Күн авылында туып-үскән ул. Авыл башында челтерәп аккан Мишә елгасының агышына сокланып, сандугачлар сайравын тыңлап хозурлана. Әтисе дә гармун уйнап җырлый торган була. Җыр-моңга тартылу нәселеннән килә ич Фаягөлнең!

«Яшь йөрәкләр» ансамбленең йөзек кашы булган Фаягөл һәр җырны күңелен биреп башкара. Чыршы мәдәният йортында оешкан ансамбльнең җитәкчесе – Азат Зәйнуллин. Фидания Яхина, Фәрит Галиев, Сәүбән Закиров, Гөлфия Хәйруллина – Фаягөл кебек, җыр-моңга гашыйк кешеләр. Төрле оешмаларда, район-шәһәр мәдәни чараларында, хәйрия концертларында катнаша алар. Замандашлары белән рәхмәткә күмелеп яши Фаягөл. Алар, ансамбльләре белән «Казан сөлгесе», «Мирас» фестивальләрендә катнашып, лауреат исеме алганнар. Комсомолның 100 еллыгына багышланган җыр конкурсында, Россиянең төрле шәһәрләрендә узган татар җыры фестивальләрендә дипломнар белән бүләкләнгәннәр. Чыршы авылы мәдәният йорты җитәкчесе Лилия Гәрәевага бик рәхмәтле алар. «Яшь йөрәкләр» ансамбле «Балкыш» республика үзешчәннәр фестивалендә дә даими катнашалар, бу бәйрәмне үз чыгышлары белән бизиләр.

Барысы да уңган-булган бу затлар, хезмәт ветераннары – җыр-моңга гашыйк затлар! Тормыш кыйбласы – кешеләргә яшәү көче, яктылык өстәү аларның!

Равилә МӨБАРӘКШИНА

Табигать нигъмәте

Ташкабак

Ташкабакның файдалы яшелчә, калий, фосфор һәм кальций чыганагы икәнен белгән бакчачылар аны ел саен күпләп үстерә. Ташкабак организмны күп төрле витаминнар белән туендыра, бигрәк тә анда С һәм В витаминнары шактый. Ташкабакны балалар ризыгына, савыгып баручы авырулар рационына кертергә һәм ашказаны белән интегүче кешеләргә бирергә була. Аз калорияле булуы һәм җиңел үзләштерелүе аркасында ул ябыгырга теләүчеләр өчен дә бик шәп ризык булып тора. Ташкабактан бихисап тәмтом, ашамлыклар ясарга, пешерергә була.

vk.com

Кышка салат

1 кг помидор, 2 аш кашыгы тоз, 1 стакан көнбагыш мае, 1 стакан шикәр, 3–5 данә болгар борычы, 2 данә кызыл әче борыч, 3 кг ташкабак, 100 грамм сарымсак, 1 аш кашыгы серкә эссенциясе кирәк.

Помидорларны шакмаклап турарга һәм кәстрүлгә салырга. Аннары шунда тоз, көнбагыш мае һәм шикәр өстәргә. Барлык катнашманы кайнатырга. Болгар борычын һәм кызыл әче борычны саламлап турарга. Ташкабакны 5 мм киңлектә түгәрәкләп кисеп, 4–6 өлешкә бүләргә.

Кайнап торган помидор катнашмасына барысын да салырга. Кайнатып чыгарырга һәм 30 минут кайнатырга. Әзер булырга 5 минут калгач, аш серкәсе һәм вак итеп туралган сарымсак кушарга. Стерильләштерелгән банкаларга кайнар килеш тутырырга. Банкаларны төреп куярга.

«АНКЛ-БЕНС» САЛАТЫ

2 кг ташкабак, 300 грамм суган, 5–6 данә болгар борычы, 1 кг помидор, бер стакан көнбагыш мае, 200 грамм шикәр комы, 200 грамм томат пастасы, 1 аш кашыгы тоз, 2 аш кашыгы аш серкәсе кирәк.

Көнбагыш маен, шикәр, томат пастасын 10 минут кайнатканнан соң, вак итеп шакмаклап туралган ташкабак һәм суган өстибез дә тагын 10 минут кайнатабыз. Аңа вак итеп туралган татлы борыч салабыз, 10 минут кайнатканнан соң, тоз, помидор, серкә салабыз. 10 минут пешерәбез дә кайнар салатны стерильләштерелгән банкаларга тутырабыз.



Нияз Бишбалта

ҖАВАПЛАР. Горизонталь буенча: бурсык, саз, Ока, балак, шапшак, хек, ани, кеш, эрә, мут, саклагыч, әче, кул, үле, җәйрән.
Вертикаль буенча: белешмә, күчерма, плита, сәке, җилак, кабак, ак, солых, гамак, көз, тишек, чолан.

КАЙНАТМАЛАР

Лимонлы

vk.com

1 кг ташкабак, 800 грамм шикәр комы, 1 лимон кирәк.

Ташкабакларны вак-вак шакмакларга турарга, шикәр комы салып, 10–12 сәгатькә калдырырга кирәк. Лимонны кабыгыннан әрчергә һәм шулай ук вак итеп турарга. Ташкабакларны, кайнап чыккач, 15 минут пешерергә, аннан соң лимон салырга һәм тагын 15 минут кайнатырга кирәк. Әзер кайнатманы стерильләштерелгән банкаларга тутырырга һәм ябарга.

Кайнатмага лимон белән әфлисунны бергә кушсаң да була. Шулай ук күрәгә белән дә бик тәмле килеп чыга. 1 кг ташкабакка 150 грамм күрәгә кушыла.

Әфлисунлы

vk.com

Ташкабак кайнатмасы бик гади әзерләнсә дә, телне йотарлык тәмле була. Аны берничә төрле ысул белән кайнатырга мөмкин. Әфлисунлы ташкабак кайнатмасы өчен 1 кг эре ташкабак, 4 стакан шикәр комы, 3 әфлисун кирәк.

Ташкабакларны юасың, кабыгыннан, орлыкларыннан арындырасың һәм эре угычтан уасың. Эмаль савытка салып, шикәр комы белән бутаганнан соң 4–6 сәгатькә суыткычка куеп торырга кирәк. Аннан соң шикәрле ташкабакны даими болгатып кайнатып чыгарасың да тагын 20 минут сүрән утта тотасың. Уттан алып кайнатманы суытырга һәм 4 сәгатькә салкынча урынга куярга. Икенче кат утка куйгач, кайнатма кайнап чыгу белән, аңа чистартылган һәм вак итеп туралган әфлисун өстәргә һәм 15 минут пешерергә кирәк. Кайнатманы тагын дүрт сәгать «ял иттерәбез» һәм, өченче тапкыр кайнатып чыгаргач, банкаларга тутырабыз. Аны күпләр сироптагы ананас дип кабул итә.

ТУТЫРЫЛГАН ТАШКАБАК

vk.com

Ташкабакны бер сантиметр калынлыкта тәгәрмәчләп турап, эчендәге орлыкларны алыгыз. Эченә борыч, кыздырылган суган салынган ит фаршы тутырып, майланган табага тезәргә. Ташкабакларның өстенә телемләп помидор куярга да мөмкин. Өсләренә каймак салырга, угычтан уылган сыр сибәргә һәм духовкада пешерергә. Фарш урынына яшелчәләр белән дөге тутырырга да була.

Файдалы крем

Ташкабакның йомшак эчен боламык рәвешенә китереп изегез. Куе каймак хәленә килгәнче сөт кушып болгатыгыз һәм битегезгә сылагыз. 20 минуттан битлекне сөртеп алыгыз да битегезне салкын су белән юыгыз. Бу – нормаль тире өчен. Шәлперәя башлаган тирегә угычтан уылган ташкабак йомшагын марля аша куярга. 15–20 минуттан җылы су белән юарга. Файдалы да, арзанлы да битлек.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru